**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасында Ярлыкау мәсьәләләре комиссиясе турында нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә ярлыкау мәсьәләләре комиссияләре турында» 2001 елның 28 декабрендәге 1500 номерлы Указы нигезендә һәм Татарстан Республикасында Ярлыкау мәсьәләләре комиссиясе эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасында Ярлыкау мәсьәләләре комиссиясе турында кушымтада бирелүче нигезләмәне расларга.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2017 ел, 04 сентябрь
№ ПУ-781

Татарстан Республикасы
Президентының
2017 елның «_04_» сентябрендәге
ПУ-_781_ номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасында**
**Ярлыкау мәсьәләләре комиссиясе турында**
**нигезләмә**

1. Татарстан Республикасында ярлыкау мәсьәләләре комиссиясе (алга таба – Комиссия) хөкем ителгәннәрне ярлыкау турында үтенечнамәләрне алдан карап тикшерү һәм ярлыкау актын куллануның максатка ярашлылыгы турында Татарстан Республикасы Президенты өчен бәяләмә әзерләү буенча даими эшләүче орган булып тора.

2. Комиссия Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

3. Комиссиянең төп бурычлары түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасы территориясендәге җәзаларны үтәтү учреждениеләрендә хөкем ителгәннәрне, тикшерү изоляторларында утыручы, тикшерү гамәлләрендә яисә судта тикшерүдә катнашуга җәлеп ителгән хөкем ителгәннәрне, шулай ук суд билгеләгән җәзаны үтәгән һәм суд хөкеменә тартылуы әле көчендә булган затларны ярлыкау турында үтенечнамәләрне алдан карап тикшерү;

ярлыкау турындагы материаллар буенча алга таба Татарстан Республикасы Президентына тапшыру өчен бәяләмәләр әзерләү;

Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе Президентының ярлыкау мәсьәләләре буенча указларының вакытында һәм дөрес итеп үтәлүенә, шулай ук хөкем ителгәннәрне җәзага тарту шартларына җәмәгать контролен башкару;

Татарстан Республикасы территориясендәге җәзаларны үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнарының, башка дәүләт органнарының хөкем ителгәннәрне ярлыкау, шулай ук җәзаларны үтәгән затларның социаль җайлашуы мәсьәләләре буенча эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру турында тәкъдимнәр әзерләү.

4. Комиссия составы Комиссия рәисеннән, Комиссия рәисе урынбасарыннан һәм Комиссия әгъзаларыннан формалаштырыла.

Комиссия составын Татарстан Республикасы Президенты раслый.

Югары белеме булган, гражданнарның хөрмәтен казанган һәм намусына тап төшермәгән Россия Федерациясе гражданнары Комиссия әгъзасы була ала. Комиссия составының ким дигәндә өчтән ике өлеше җәмәгатьчелек вәкилләреннән төзелә һәм ике елга бер тапкыр аның өчтән бере яңартылырга тиеш. Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары һәм Комиссия әгъзалары эшчәнлекләрен җәмәгать башлангычларында алып баралар.

5. Комиссия эшчәнлегенә Комиссия рәисе җитәкчелек итә.

Комиссия рәисе:

Комиссия утырышларын алып бара;

Комиссиянең бәяләмәләренә, шулай ук соратуларына һәм хатларына кул куя;

хөкем ителгәннәргә Россия Федерациясе Президенты тарафыннан ярлыкау турындагы үтенечнамәләрнең кире кагылуы хакында язма рәвештә хәбәр итә.

Комиссия рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

6. Әгәр анда Комиссия әгъзаларының яртысыннан ким булмаган өлеше катнашса, Комиссия утырышы гамәлгә хокуклы дип санала.

Комиссия утырышларының күпме вакыт аша уздырылуы ярлыкау турындагы үтенечнамәләрнең бирелүенә бәйле билгеләнә. Үтенечнамә алынган көннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча, Комиссия Татарстан Республикасы Президентына хөкем ителгән затка карата ярлыкау актын куллануның максатка ярашлылыгы турында бәяләмә бирә.

7. Үз алдында торган бурычларны хәл итү өчен Комиссия җәзаларны үтәтү учреждениесе яисә органы администрациясеннән (тикшерү гамәлләрендә яисә судта тикшерүдә катнашуга җәлеп ителгән хөкем ителгәннәргә карата – тикшерү изоляторы администрациясеннән), Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнарыннан, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарыннан хөкемгә тартылган затны ярлыкау турындагы материаллар әзерләү өчен кирәкле өстәмә белешмәләр һәм документлар соратырга һәм алырга хокуклы.

8. Комиссиянең карарлары аның утырышта катнашучы әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар саны тигез булганда, Комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып санала.

Комиссия утырышы йомгаклары буенча беркетмә төзелә, аңа утырышта рәислек итүче һәм анда катнашучы барлык Комиссия әгъзалары кул куя.

Комиссия утырышы беркетмәсенә нигезләнеп ярлыкау турындагы һәрбер карап тикшерелгән үтенечнамә буенча бәяләмә тутырыла, ул

Комиссия рәисе тарафыннан имзалана һәм Татарстан Республикасы Президентына тапшырыла.

9. Комиссиянең Татарстан Республикасы гербы һәм үз атамасы язылган штампы һәм бланклары була.

10. Комиссия эшчәнлеген оештыру ягыннан тәэмин итүне Комиссия секретаре башкара. Комиссия секретаре Комиссия составына керми һәм аның тавыш бирү хокукы юк.

Комиссия эшчәнлеген матди-техник тәэмин итү Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының тиешле структур бүлекчәләре тарафыннан башкарыла.